**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2729**
**21.04.2021**

Башкарма комитетның 2019 елның 14 мартындагы 1267 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларын (балалар бакчалары) комплектлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 14 мартындагы 1267 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларын (балалар бакчалары) комплектлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы приказы» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы приказы» сүзләренә алмаштырырга; «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 8 апрелендәге 293 номерлы приказы» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы приказы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 пунктта «Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2013 елның 15 маендагы 26 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын урнаштыруга, карап тотуга һәм эш режимын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.4.1.3049-13 СанПиН» сүзләрен «Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән расланган «Балаларга һәм яшьләргә тәрбия һәм белем бирүне, ялын һәм сәламәтләндерүне оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.4.3648-20 СанПиН» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов